СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422701, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Высокая Гора, ул. Б. Красная, 113А

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИЕКТАУ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422701, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау авылы, Зур Кызыл, ур 113А

Тел./факс: +7(84365) 74-7-79, e-mail: Vgor.Vsg@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
28.06.2024

КАРАР
374

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2019 елның 29 нчы ноябрендәге 625 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

2007 нче елның 2 нче мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында», 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законнар, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2019 елның 29 ноябрендәге 625 нче номерлы (2020 елның 27 февралендәге 658 нче номерлы, 2021 елның 9 нчы сентябрендәге 118 нче номерлы, 2023 елның 19 нчы сентябрендәге 306 нчы номерлы Совет карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 статьяның 1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 12 пунктчасы белән тулыландырырга:

«12) 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетадагы мәгълүматларга билгеле булган, яллаучы вәкиле (эш бирүче) карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш (алга таба анкетада булган мәгълүматлар) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) үзгәрешләр турында язма рәвештә хәбәр итәргә.»;

1.2. 6 нчы статьяның 1 нче пунктындагы 8 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә

бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны үткән вакытта ялган документлар һәм (яисә) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүне раслаучы, яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм (яисә) таләпләрне үтәмәүне раслаучы ялган мәгълүматлар тапшыру;»;

1.3. 14 статьяның 3 нче пунктындагы 2 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкета;»;

1.4. 14 статьяның 4 пунктын «Мәгълүмат» сүзеннән соң «(анкетада булган мәгълүматлардан тыш)» сүзләре белән тулыландырырга».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасындагы мәгълүмати стендында, Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтының https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Совет рәисе,
Биектау авыл җирлеге башлыгы А.А.Хабибуллин